**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы**

**Олы Җәке авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

3 июнь 2019 ел № 160

Башка бюджетара трансфертлар хисабына
үтәлүче Зеленодольск муниципаль районы
«Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль
Берәмлекләреннән алынган һөнәри керемгә
салым буенча салым потенциалы үсешен
стимуллаштыру максатларында
чыгымнарны юнәлдерү турында

Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге Башлыгы мәгълүматын тыңлаганнан һәм караганнан соң Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елгы 28 мартындагы «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 233 номерлы Карары, Татартан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның26 апрелендәге «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турындагы» 379 номерлы карары нигезендә Олы Җәке авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1.Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалын үстерүне стимуллаштыру, Зеленодольск муниципаль районы "Олы Җәке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү, матурлауны оештыруны финанслау максатында башка бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырылучы, Яшел Үзән муниципаль районы "Олы Җәке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге тарафыннан кабул ителгән чыгымнарның юнәлешләрен расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокук мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http//zelenodolsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрдә, шулай ук, Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Олы Яке авылы, Мәктәп ур, 1а йорты (Олы Яке күп функцияле үзәк бинасы), Каратмән авылы, Клуб урамы, 23нче йорт (Каратмән авыл клубы бинасы), Уразлы авылы, Дуслык урамы, 3нче йорт (Уразлы авылы клубы бинасы) урнаштырырга.

Олы Җәке авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе Ф.А.Фәйзуллина